ГЛАВА БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
Олы МемиАВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.11.2021 с. Большие Меми № 1

Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авылындагы гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

Карар бирәм:

1. 2021 нче елның 2 нче декабрендә сәгать 10: 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2021 нче елның 2 нче декабрендә сәгать 12: 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. 2021 нче елның 2 нче декабрендә 14 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Халык исемлеген бүлү территориаль билге буенча башкарыла.

1 этап: Олы Меми авылының Яшьләр урамында яшәүчеләр

2 этап: Олы Меми авылының Гаврилов Я. А., Үзәк урамнары халкы

3 этап: Олы Меми авылының Заречная урамында яшәүчеләр, Исаев урамында яшәүчеләр

5. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2021 нче елда Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Олы Меми авылы зиратын өлешчә койма белән тотып алу.

« ӘЙЕ» «ЮК»

6. Халык җыеннарын үткәрү:

1 этап: Олы Меми авылының Яшьләр урамы буенча 18-нче номерлы йорт янында

2 этап: Олы Меми авылының Гаврилов Я. А. урамы буенча 45-нче номерлы йорт янында

3 этап: Олы Меми авылының Заречная урамы буенча 15-нче номерлы йорт янында

7. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль район
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Г. А. Фомина